ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 13 » мая 2019 г. № 11

**Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламентлар раслау**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2 ноябрь 2010 елның 880 нче карарына, Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр” 2019 ел 19 апрель 167 карарына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

1.1. Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (1 нче кушымта);

1.2 Муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәсе буенча бирелгән торак урыннарын алыштыру буенча документлар рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (2 нче кушымта);

1.3 Муниципаль милектә булган гражданга социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ регламенты (3 нче кушымта);

1.4 Адресларны бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (4 кушымта);

1.5 Документлар күчермәләре һәм алардан өземтәләр тугрылык таныклавы буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (5 нче кушымта);

1.6 Нотариаль гамәлләр башкару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты: васыять таныклыгы һәм ышаныч таныклыгы (6 нчы кушымта);

1.7 Мирас мөлкәтен саклау буенча чаралар күрү һәм кирәк булган очракта аларга идарә итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (7 нче кушымта);

1.8 Документларда имзаларның чынлыгын таныклау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (8 нче кушымта).

1.9 Белешмәләр (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (9 кушымта);

1.10 Агач кисүгә һәм куаклар утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (10 нчы кушымта);

1.11 Муниципаль милектә булган җирләрдә стационар булмаган сәүдә объектларын аукцион уздырмыйча урнаштыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (11 нче кушымта).

1.12 Ваклап сату базарын оештыру хокукына рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты (12 нче кушымта).

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башкарма комитетының «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2013 елның 19 апрелендәге 9 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга (15.06.2012 ел № 3, 28.01.2014 ел № 4; 25.09.2015 ел № 17; 10.05.2016 ел № 4, 23.06.2017 ел № 15 үзгәрешләр белән).

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (baltasi.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үзем артыннан калдырам.

Норма авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе — И. И. Мөбәрәкшин